ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 25

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә сәгать 9.00 сәгатькә Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылырга тиешле сорауны расларга:

2020 елда Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән кала, 200 сум күләмендә үзара салым тапшыру һәм аларны түбәндә күрсәтелгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны  Яңа Чыршылы авыл җирлеге Горкино авылында урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы Р. Ә. Мөхәмәтшина